**Белем һәм тәрбия мәсьәләләрен хәл итүдә балалар әдәбияты: чор, җәмгыять һәм шәхес**

Л.И.Миңһаҗева,

филология фәннәре докторы, КФУ доценты

Summary. The twenty – sirst century puts more and more difficult problems to the educational system. Main of them if is that the yound generation must be well – educated and well-bred. The worka of Children literature heer us to solve these problems.

**Key words:** Tatar child's literature, education, the issue of education, society and identity

XXl гасыр югары уку йортлары алдына көннән-көн катлаулырак бурычлар куя. Җәмгыятьнең сәяси-хокукый системасындагы үзгәрешләр, икътисадый, иҗтимагый һәм демографик хәл мәгариф системасында да яңалыклар таләп итә. Бүгенге көндә, һәр дәвердәгечә, яшь буынны белемле һәм тәрбияле итү дәүләт алдында торган иң мөһим мәсьәләләрнең берсе. Мәгълүм ки, киләчәк яшәеш аларның әхлагы, гореф-гадәтләргә, йолаларыбызга булган мөнәсәбәте белән бәйләнә.

Гомум билгеле, бала беренче чиратта гаиләдә тәрбияләнә. Биредә аның иң якын кешеләре: әти-әнисе, әби-бабасы һәм туганнары. Гаиләдә ул беренче тапкыр мәхәббәт, тугърылык кебек төшенчәләр белән таныша. Алга таба бакча, мәктәп, югары уку йортлары, коллектив, ягъни тирәлек, җәмгыятьнең төрле кешеләре белән аралашу. Шушы этапларда, формалашу дәвамында әдәби әсәрләр аша тәрбия — мөһим чара. Бу нисбәттән, балалар әдәбияты әсәрләре аеруча әһәмиятле. Чөнки ул — әдәбият һәм педагогиканың синтезы. Мәгълүм ки, тематика, тел һәм стиль мәсьәләләре, сюжет проблемасы һәм эмоциональ бизәкләү дәрәҗәсе — болар барысы да билгеле бер яшьтәге балаларның специфик үзенчәлекләрен чагылдыручы күрсәткечләр. Нәкъ менә шуңа күрә бу өлкәдәге уңышлы әсәрләрне яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып дөрес куллану — әһәмиятле белем һәм тәрбия чыганагы булачак.

Уку-укыту процессында, әлбәттә, дисциплиналарның — фольклор, әдәбият теориясе, әдәбият тарихы, бала психологиясе, иҗат психологиясе, педагогика, методика, социология, эстетика һәм башка предметларның үзара фәнни бәйләнеше мәсьәләләре үзәктә булырга тиеш. Чөнки болар барысы да балада китапка мәхәббәт уяту юнәлешендә хезмәт итәчәк. Инде расланган, уй-фикер үсеше бары китаптан гына килә. Ата-аналарның балаларга игътибары киму нәтиҗәсендә бүгенге көндә «өлкәннәр — бала — китап» дигән өч төшенчә сирәк гаиләләрдә генә бергә яши. Югыйсә, иң авыр вакытларда да югары дәрәҗәдә язылган китапка мәхәббәт сүнмәгән. Нәкъ менә шуңа күрә кече яшьтән үк баланы китап белән кызыксындыру — аның киләчәк язмышында зур роль уйнаячак. Бу юнәлештә балалар әдәбияты әсәрләре зур таяныч.

Балалар әдәбияты исә үзлегеннән генә туган, аерым, үз эчендә генә яши торган мөстәкыйль әдәбият түгел, ул — гомуми әдәбиятның бер тармагы, аның белән уртак каршылыклар эчендә үсә, үз чорын, мохитен чагылдыра. Аерым тарихи чорларда аңа тәрбияви максаттан зуррак таләпләр һәм бурычлар да куела. Чөнки балалар һәм яшүсмерләр өчен матур әдәбият әсәре — зур ярдәмче һәм ышаныч та.

Балалар әдәбияты — специфик өлкә. Шуңа күрә формалашуыннан башлап, бүгенге көнгә кадәр аның тирәсендә һәрвакыт бәхәсләр бара. Бик күпләр балалар өчен «башкача» язарга кирәклеген аңлый, шул җирлектә аерым билге-сыйфатларны алга чыгара, кайберәүләр исә, гомум закончалыкларны гына кабул итә. Балалар әдәбияты «педагогика — рәсемнәрдә» кебегрәк бәяләүчеләр дә, аның төп әһәмияте эчтәлек һәм тел-стильдә дип караучылар да бар. Аерым бер төркем балалар әдәбиятының спецификасын тема билгели дигән караштан чыгып, әсәрләрдә уен, уку, балалар хезмәте яктыртылырга тиеш дип басым ясыйлар. Бу фикерне беркадәр инкарь итеп, икенче төркем укучы бала яшенә әсәр героеның яше туры килүен беренче планга чыгара. Шулай итеп, авторлар балалар әдәбиятының спецификасын тема, проблема,

әдәби образлар, укучы яшенең әсәр геройлары яшенә туры килүе һ.б. бик күп алшартлар билгеләвен ассызыклыйлар. Бу карашлар, әлбәттә, һәрберсе беркадәр дәрәҗәдә дөрес. Әмма, әдәбият белеме аспектында бу өлкәне, безнең фикеребезчә, төп ике юнәлештә өйрәнү уңышлы. Алар методологик һәм методик әһәмиятле мәсьәләләрне хәл итә.

1. Балалар әдәбияты – барлык әдәби таләпләрне, гомуми функцияләрне үтәүче сүз сәнгате. Әмма бер үк вакытта ул әхлакый–педагогик та.

Алдарак билгеләп үтелгәнчә, еш кына гадәти педагогик күзаллау буенча аның шушы ягына зуррак игътибар бирелеп, башка функцияләре төгәл бәяләнмәде.

2. Балалар өчен әсәрләрнең әдәбилек критерийлары мәсьәләсе. Ул турыдан–туры балалар әдәбиятының үзенчәлеге белән бәйле. Проблемага төгәлрәк якын килсәк, балалар әдәбияты – әдәбилек критерийларына тулаем туры килүче, укучыларның яшенә күрә тәрбиясенә, интеллектуаль һәм рухи сыйфатлары үсешенә тәэсир итүче сүз сәнгате. Аңлашыла, төп идея–фикер әдәбилекне һәм тел–стильне начарайту хисабына үткәрелергә тиеш түгел. Балалар өчен матур әдәбият үзенчәлеген аңлау – димәк, әдәби сурәтлелекне һәм фикерне балаларча әйтә белү осталыгына ирешү.

Балалар әдәбиятының үзенчәлеге баланың яшенә карап та ачыклана. Әсәрдәге герой һәм укучы бала – формалашучы шәхесләр. Аларның фикер сөреше, яшәешне кабул итүе, тормыш тәҗрибәсе өлкәннәрнекеннән үзгә, шуңа өстәп, еш һәм даими үзгәрүчән. Язучы әсәрен якынча нинди яшьтәгеләргә тәкъдим ителәсен ачык күзаллап иҗат итәргә тиеш. Чөнки яшь үзенчәлекләре саклану мәҗбүри. (Дөрес, яшь ягыннан бер үк чамадагы балалар да бер-берсеннән байтак дәрәҗәдә аерылырга мөмкин. Мисалга, М.Җәлилнең дүртьеллык башлангыч белемне бер елда үзләштерүе турында истәлекләр сакланган, унөч яшеннән үк шигырьләренең матбугатта басылуы да билгеле). Ягъни, мондый шартларда балалар язучысы алдына зурлар әдәбиятына хас булмаган бурыч килеп баса – укучының яшь үзенчәлеген, мөмкинлекләрен истә тоту.

Бу очракта балалар әдәбиятын төп дүрт баскычка бүлеп өйрәнү максатка яраклы:

1. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен әдәбият. Ул уенга нигезләнгән, уенчыл характерда язылырга тиеш. Чөнки бала уен уйнап яшәеш, кешеләр һәм хезмәт белән таныша. Уен барышында аның әхлакый–психологик сыйфатлары һәм ихтыяр көче формалаша, рухи һәм физик яктан үсә. Бу яшьтәге балалар таныш сүзләр аша эмоциональ югарылыктагы әсәрләрне яраталар, аларны җиңел такмаклар, аваз ияртемнәре, сюжетлы шигырьләр, экиятләр, кыска күләмле маҗаралы әсәрләр һәм тизәйткечләр кызыксындыра.

2. Түбән звено – сабыйлык чорының икенче баскычы. Бала күңеленең «чиста дәфтәр» чоры. Тормышта ике генә төсне кабул итәләр: «ак» һәм «кара». Шуңа күрә бу яшьтәге (якынча 7–11 яшьләр) балаларга тәкъдим ителә торган уңышлы әсәр аларның чынбарлык турындагы белемнәрен арттыруга корыла. Әкиятләрне, яшьтәшләре тормышыннан алып язылган кызыклы вакыйгалар турындагы хикәяләрне, юмористик әсәрләрне яратып укыйлар.

3. Урта звено – иң авыр чор. Физик һәм рухи яктан зур үзгәрешләр чоры. Характер, тормышка карашлар үзгәрә, мин–минлек көчәя һ.б. Әдәбият та бу чорда бала таләпләренә җавап бирергә тиеш: үрнәк алырдай идеал, аның кебек булу омтылышы зур роль уйный.

4. Югары звено – яшүсмерләр әдәбияты. Югары сыйныф укучыларын үз эченә ала. Бу яшьтәге балаларда кешеләрнең психологиясен тирәнтен аңларга омтылыш көчәя. Күбрәк үзләренең киләчәк тормышлары, яшәү рәвеше, профессия сайлау, мәхәббәт турында уйланалар. Өлкәннәрнең бурычы – балага киңәшче булу. Әсәрләргә тормышчан анализ ясау аша, яхшы һәм начарны төгәл билгеләү, эш–һөнәрле кешенең генә кадерле булуын аңлату һ.б.

Шулай итеп, балалар язучысы өчен әһәмиятле моментларның берсе – укучысының тәҗрибәсен, фикер сөрешен күзаллау, яшен, тормышны кабул итү үзенчәлекләрен төгәл төшенү булды.

Татар балалар әдәбияты турында сөйләшкәндә шуны ассызыклап үтү зарур: алда саналганнардан тыш аның үзенә генә хас аерым специфик сыйфатлары бар. Мисалга, татар балалар әдәбиятының тематикасы милли менталитет белән тыгыз бәйләнештә. Балалар язучылары әсәрләрендә милли үзенчәлекләрне, милли характер сыйфатларын, гореф-гадәтләр һәм традицияләрне һ.б. еш һәм тыгыз яктырталар. Мисалга, татар халык легенда һәм риваятьләренә, әкиятләренә нигезләнеп язылган күп кенә әсәрләрдә (Ф.Әмирхан, А.Алиш, Н.Исәнбәт, Б,Рәхмәт, И.Туктар, Т.Миңнуллин, Ф.Яруллин, Г.Гыйльманов һ.б.) туган ил һәм патриотизм, тарихи темалар, милли үзенчәлекләр аша үткәрелә, вакыйгаларда татар милләте вәкилләре өчен горурлык сизелә. Төп герой һәм пәһлеваннар — милли көч символы. Аллегория кулланып тудырылган образлар башкалар арасыннан көче, матурлыгы, алга омтылышы белән характерлана. Шунда ук татар халкының күңел матурлыгы, кунакчыллыгы ачыла. Аерылып торучы мондый персонажлар нигездә уңай сыйфатлары белән генә ачылалар. Авторлар үрнәк образ аша төп тәрбияви максатка ирешергә омтылалар. Әкияти сыйфат һәм вакыйгаларның чынлык белән бәйләнүе исә укучының кичерешләренә дә уңай тәэсир итә.

Әкияти һәм реальлекнең тыгыз бәйләнеше әсәрләрнең спецификасын тудыра. Ягъни, татар балалар язучылары легенда һәм риваятьләр, әкияти сюжетлар һәм хәзерге яшәеш арасында параллельлек үткәрергә омтылалар. Бу хәл мәгънәгә тирәнрәк үтеп керергә, халык, тарих белән горурланырга мөмкинлекләр ача. Мондый әсәрләрдә төп геройлар бөтен бер персонажлар системасын специфик итә. Алдарак билгеләп үтелгәнчә, нәкъ менә алар динамикада, үсештә һәм алар — сюжетны хәрәкәткә китерүче көчләр, үзәк. Мәгълүм булганча, татар балалар тоэзиясендә һәм прозада да хатын-кыз, ана образы үзенчәлекле ачыла. Гасырлар дәвамында бу образ хөрмәт белән бары

тик ак төсләрдә генә, изге итеп сурәтләнде. Мисалга Г.Тукай, Г.Исхакый, Һ.Такташ, Ф.Кәрим, Р.Миңнуллин, Г.Гыйльманов һ.б. иҗатларын китерергә мөмкин. Аерым авторлар — Г.Тукай, М.Җәлил, Б.Рәхмәт, Ш.Галиев, Р.Вәлиева, Х.Халиков һ.б. еш кына әсәрләрен укучы алдына сорау куеп тәмамлыйлар. Бу да үзенчәлекле күренеш. Чөнки уңышлы куелган сораулар укуны кызыклы һәм шатлыклы итә, аңа бала чын күңелдән җавап табарга омтыла, канәгатьлек хисе кичерә. Чөнки автор аны зур һәм акыллы кешегә санап сорау бирә.

Татар балалар әдәбияты әсәрләренең стиле дә специфик үзенчәлекле. Әсәрләрдә милли исемнәр, халык көнкүрешендә кулланылучы сүзләр, шулай ук аңа гына хас символизм бар. Һәр әсәрдә диярлек бер предмет яки образ үзендә аерым бер символик мәгънә йөртә. Алар нигездә — Яхшылык, Хаклык һәм Матурлык төшенчәләрен яктырталар. Шулай итеп, татар балалар әдәбияты традицион да, специфик үзенчәлекле дә. Ул әдәби һәм мәдәни мирасның бер өлешен, бөтенкешелек кыйммәтләрен үзендә саклый. Әлеге кыйммәтләр исә балалар аңын гуманлы итү, кечкенә шәхесне тормыш юлын дөрес сайларга өйрәтү өчен тудырылган.

Балалар әдәбиятының тормышта, белем һәм тәрбия юнәлешендә тоткан урыны турындагы бәхәсләр еллар аша еш кабатланып тора. Бу хәл әдәби даирәгә яңа карашлы яшь буын авторлар килү, кешелек җәмгыятенең, яшәешнең бик тиз үзгәрә баруы белән дә бәйләнгән булса кирәк.

Әдәбият:

1. Балалар әдәбияты турында җыентык / төз. З.Нури. — Казан: Татар. кит.нәшр., 1959.

2. Кәрим Ф. Балалар әдәбияты турында / Ф. Кәрим. Әсәрләр. 3 томда. Т.3. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1981.

3. Муса турында истәлекләр / Төз. һәм әдәби эшкәртүче Г.Кашшаф. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1964.

4. Сухомлинский В. Родительская педагогика / В.Сухомлинский. — М.: Знание, 1978.